РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
Агерзинского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Әгерҗе авыл җирлеге Советы
**БАШЛЫГЫ**

ул. Г. Ахметова, д. 14а, село Агерзе,
Азнакаевского муниципального района, 423303
Тел. (факс) 8(8-5592) 44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

Г. Әхмәтова урамы, 14а, Әгерҗе авылы
Азнакай муниципаль районы, 423303
Тел. (факс) 8(8-5592) 44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«04» октябрь 2022 ел № 3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Әгерҗе торак пунктында гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Әгерҗе авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2022 елның 16 октяберендә 09 сәгать 00 минутта үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә:Яшьләр урамы. Үткәрү урыны: Яшьләр урамы, 23 нче йорт каршында.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Әгерҗе авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2022 елның 16 октяберендә 11 сәгать 00 минутта үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә:Г.Гафиятуллин урамы, Г.Ахметова урамы 15 йорттан 24 йортка кадәр Үткәрү урыны: Гафиятуллин урамы, 24 нче йорт каршында.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Әгерҗе авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2022 елның 16 октяберендә 14 сәгать 00 минутта үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә: Г.Ахметова урамы 1 йорттан 14 йортка кадәр, Г.Тукай урамы 1 йорттан 26 йортка кадәр, С.Сайдаш урамы 1 йорттан 24 йортка кадәр, С.Хакима урамы 1 йорттан 48 йортка кадәр. Үткәрү урыны: мәдәният йорты.

4. Билгеләү:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Әгерҗе торак пунктында үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- халык җыенын үткәрү вакыты-2022 елның 16 октябере 09.00 сәгатьтән 10.00 сәгатькә кадәр;
- халык җыенын үткәрү вакыты-2022 елның 16 октябере 11.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр;
- халык җыенын үткәрү вакыты-2022 елның 16 октябере 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;
- җыенны үткәрү урыны-Әгерҗе авылы, Яшьләр урамы, 23 йорт каршында;

- җыенны үткәрү урыны-Әгерҗе авылы, Г.Гафиятуллин урамы, 24 йорт каршында;
- җыенны үткәрү урыны-Әгерҗе авылы, мәдәният йорты.

5. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2022 елның 11 октябереннән дә соңга калмыйча гражданнар, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыенын хәл итүгә чыгарылучы материаллар белән танышу хокукына түбәндәге адрес буенча ия: Әгерҗе авылы, Г. Әхмәтова урамы, 14а йорт;
- Әгерҗе торак пунктында сайлау хокукына ия яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Әгерҗе торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итү.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Әгерҗе авыл җирлеге Әгерҗе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булганнардан 650 сум күләмендә, 1 төркем инвалидларыннан, гаилә әгъзалары өлешчә мобилизациягә чакырылган гражданнарыннан, түләүне бер тапкыр киметеп 80 яшьтән өлкән пенсионерлар өчен 500 сум күләмендә үзарасалым кертү һәм бу акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Әгерҗе авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (юлларга вак таш сатып алу, таш салу, таш җәю, Г.Ахметова урамы, килешү буенча эш өчен түләү);
- җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияне механикалаштырып, триммер белән чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, килешү буенча эшләр, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу);
- Әгерҗе авылы мәдәният йорты территориясена койма кую өчен материаллар сатып алу, койманы кую;
- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Корбан бәйрәме», «Яңа ел " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү, спорт чаралары.»);
- ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;
- трактор йөртүчесенә хезмәте өчен түләү.

« РИЗА» «КАРШЫ»

7.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Әгерҗе авылы, Г.Ахметова урамы, 1 йорт адресы буенча, Әгерҗе авылы, С.Хаким урамы, урам чатында, Әгерҗе авылы, Г.Гафиятуллина урамы, 10 йорт белән 23а йорты арасында урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

8. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык АГЕРЗИНСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1602002575 КПП 164301001 Н.Н.Хәсәнов